СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

с. Верхний Услон

09.06.2025 № 59-758

Аерым категория затларга чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны тыю турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның булуын, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып, Югары Ослан муниципаль районы Советы карар итте:

1. Аерым категория затларга чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны тыю турындагы нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е. А. Варакин